РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА СТАРОГРИШКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
МЕНДЕЛЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Ул.Молодежная, д.1, с.Старое Гришкино,
Менделеевский район, Республика
Татарстан, 423642

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ИСКЕ ГРИШКИНО АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Яшьләр ур, 1 йорт,
Иске Гришкин авылы, Менделеевск
районы,
Татарстан Республикасы,423642

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

№4 | 07.03.2025 ел.

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино торак пунктында “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 2024 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында” 2024 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү буенча гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Иске Гришкино авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 22 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы « Иске Гришкино авыл җирлеге” башлыгы
КАРАР БИРӘ:

1. 2025 елның 18 мартында 16.00 сәг. ТР, Менделеевск муниципаль районы, Иске Гришкино торак пункты, Яшьләр урамы, 1 йорт адресы буенча урнашкан Иске Гришкино авыл мәдәният йорты бинасында “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 2024 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында” 2024 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертү буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында” 2024 елның 18 ноябрендәге 1 номерлы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино торак пунктында 2025 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү турында” 2024 елның 18 ноябрендәге 2 номерлы карарларына үзгәрешләр кертергә һәм чараларны түбәндәгечә бәян итәргә Сез ризамы?” дигән сорауны расларга.

«1) Торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Азин, Елга аръягы урамнарына, зиратка кадәр юлга, скважинага кадәр юлга вак таш сатып алу/илтү һәм вак таш салу (транспорт хезмәтләре күрсәтү), кышкы чорда юлларны чистарту);

2) су белән тәэмин итү һәм ташу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Иске Гришкино т. п. скважинасын ремонтлау);

3) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (үлән чабу, зиратта агачлар кисү, триммер сатып алу)?»

«Риза» «Каршы».

3. Әлеге карарны Иске Гришкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://mendeleevsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми сайтында (реер/ / pravo. tatarstan.ru) бастырып чыгарырга

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көненнән үз көченә керә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы ____________ К.И.Алексеев
(имза) (имзаның аңлатмасы)